Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Аксумла авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

**12 ноябрь 2022 ел** **№ 10**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Аксумла авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. Әхмәт авыл җирлеге Аксумла авылында яшәүче 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, ялгыз яшәүче 75 яшьтән өлкәнрәкләрдән кала 2023 елда балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы тоту;
- су белән тәэмин итү чыганакларына карата норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

Халык җыенында рәислек итүче: Г.Н. Лизратова

Әхмәт авыл җирлеге башлыгы Г.Н. Лизратова